КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 27 октябрь г.Казань № 963

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 – 2022 елларда авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары исемлеген раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1274 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Мәгариф» илкүләм проектының «Һәр баланың уңышы» федераль проекты кысаларында 2021 – 2023 елларда авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чараларын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 – 2022 елларда авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары исемлеген раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1274 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2021 – 2023 елларда авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары исемлеген раслау турында»

карарның преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2021 – 2023 елларда авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чараларын тормышка ашыру максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт

программасын раслау турында» 2017 елның 26 декабрендәге 1642 номерлы карары белән расланган «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында «Мәгариф» илкүләм проекты составына керә торган «Һәр баланың уңышы» федераль проекты күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән 2021 – 2023 елларда авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары исемлеген расларга.»;

әлеге карар белән расланган 2021 – 2023 елларда авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары исемлеген яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин